РИЗЫКЛЫ АВЫЛ
Сала кешесе шөкер итәргә күнеккән

> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Президенты имзалаган яңа законнар

> 3

КӨЧЛЕ РУХЛЫЛАР
Бу гаиләдә беркем дә зарлануны белми

> 4

ЭШНЕҢ ОЯТЫ ЮК
Олег Волковның хатын-кыз башкарган бар эш тә кулыннан килә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 40 (28813) | Чәршәмбе | 23 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

СӨЙЛӘШКӘНДӘ ТЕЛ БАР

И туган тел

«Район башлыгының туган телгә мөнәсәбәте нинди, аның районында да шундый мохит булачак. Җитәкчеләрнең шәхси үрнәге – гади халык өчен зур мәртәбә. Бу мәсьәлә игътибарда булачак». Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышында комиссия рәисе Марат Әхмәтов әнә шулай диде. Бакча, мәктәп булсынмы – ул бар җирдә дә милли җанлы җитәкчеләр хакында хыяллана.

tatarstan.ru

– Дәүләт органнары, министрлыклар, районнар эшчәнлегендә татар теле тәҗрибәсен киңәйтү, рәсми сайтларда, социаль челтәрләрдәге аккаунтларда мәгълүматның ике дәүләт телендә дә алып барылуына басым ясыйбыз. Тәкъдимнәребез игътибарсыз ук калмады, без теләгән нәтиҗәгә ирештек дип әйтә алмыйм, әмма җитәкчеләрнең чыгышларында туган тел ешрак яңгырый башлады. Моны уңай күренеш буларак әйтәм. Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен республиканың дәүләт телләре, мәдәнияте, тарихыннан олимпиада оештырырга ниятебез бар. Бу чара да дәүләт хезмәтендә татар теленең кулланышын арттырырга йогынты ясар дип өметләнәбез, – диде Марат Әхмәтов.

Комиссия ярдәме белән төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең сөйләм теле осталыгын үстерү буенча мастер-класслар уздырылган. Әдәби-музыкаль проектлар тормышка ашырылган, теләгән һәрбер кеше өчен бушлай татар теле курслары оештырылган. Элмә такталарның, күрсәткечләрнең хаталы язылган очракларын ачыклау буенча бәйгедә республика халкы актив катнашкан. 3 меңнән артык гариза кабул ителеп, хаталар төзәтелгән. Олы юл чатларында, район үзәкләрендә туган телләргә багышланган баннерлар урнаштырылган. Казан шәһәренең проектлары да игътибарга лаек. Татарчага сөйләшергә өйрәтүче видеороликлар, паркларда «Хәрәкәттә – бәрәкәт» дәресләре, метрода туган телләр поезды, татар теле укытучылары өчен семинарлар... Марат Әхмәтов бу проектларның дәвамлы булуына өметләнә.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин милли мәгарифтәге уңышларга һәм авырткан урыннарга тукталды. Милли мәгарифкә зур игътибар бирүчеләрдән Актаныш, Апас, Арча, Әтнә, Балтач, Чүпрәле, Кайбыч районнарын атады. Менделеевск районында күрсәткечнең бик түбән булуын, Югары Осланда туган телдә белем һәм тәрбия бирү бөтенләй оештырылмавын әйтте. Әлмәт, Баулы, Зәй, Лениногорск, Менделеевск, Чаллы, Түбән Кама, Нурлат, Питрәч, Чистай районнары җитәкчеләреннән бу мәсьәләгә игътибарны арттыруны сорады. «Бу вакытлыча гына акция була алмый. Моны һәрберебез аңларга тиеш», – диде министр.

Әти-әниләргә, мәктәп җитәкчелегенә дә әйтер сүзе бар министрның. Моны ул киләсе уку елыннан гамәлгә керәсе стандартларга бәйләп аңлатты.

– Узган ел Россия Мәгърифәт министрлыгы боерыгы белән башлангыч, төп белем бирүнең яңартылган стандартлары расланды. Анда Россия Федерациясе республикаларының дәүләт телен сайлап алу мөмкинлеге бар һәм ул уку планының мәҗбүри өлешендә булган туган тел һәм әдәбият предметы өлкәсенә кертелгән. Закон нигезендә белем бирү һәм туган телне әти-әниләр сайлый. Стандартларда рус телендә белем бирүче мәктәпләр өчен Россия халыклары телләре һәм республикаларының дәүләт теле, уку йортының мөмкинлекләреннән чыгып, әти-әниләренең гаризасы буенча гамәлгә ашырыла дигән искәрмә куелган. Бу исә әти-әниләр туган телне сайламаганда, туган телнең мәҗбүрилеген инкяр итә һәм каршылык китереп чыгарырга, кызганыч хәлгә китерергә мөмкин. Тел мәсьәләсен искәрмәләр белән генә хәл итеп булмый. Хәзерге вакытта Россия Мәгариф академиясенең Мәгарифне үстерү стратегиясе институты төп белем бирү программаларының якынча проектларын эшләде. Әле уку планының кайбер вариантларында туган тел һәм әдәбиятны өйрәнү төшереп калдырылган. Россия мәгърифәт министры исеменә туган телләрне укыту оештыру буенча программаларга төзәтмәләр кертү кирәклеге турында хат юлланды, – диде Илсур Һадиуллин.

Республиканың баш педагогы белдергәнчә, балада туган телне өйрәнүдә кызыксыну уяту өчен, белем бирү барышы мавыктыргыч булырга, уңай хисләр уятырга тиеш. Бүген федераль исемлеккә 89 дәреслек кертелгән. Татар теленнән 12 әсбап, яңа буын дәреслекләр һәм 1–4 сыйныфлар өчен математикадан тәрҗемә дәреслек федераль исемлеккә кертү өчен лаеклы дип табылган.

– Бу – безнең өчен беренче җиңү. Барлыгы 20 дәреслек. Алга таба эшлисе эшләребез, калган дәреслекләрне ахырына җиткерәсе бар. Бу – бик катлаулы эш. Боз кузгалды, кузгалган бозны туктатып булмый, ул кая да булса килеп бәрелә, я бәреп чыга. Бәреп чыгуны мин яхшы мәгънәдә әйтәм. Башланган эшләр бара дигән сүз, – ди министр. – Әти-әниләр, әби-бабайлар, татар теле язмышына шикләнеп карауучыларга шуны әйтәсе килә: «Милләт яшәгәндә, тел бетми». Бер генә әйбер – өйдә туган телдә сөйләшү сорала. Аннан ул мәктәптә дәвам иттерелә. Моны мәктәпкә генә сылтасаң, булмый. Укытучылар, тәрбиячеләр дә, дәреслекләр дә бар. Телевидение дә эшләп тора. Булган рухи байлыктан файдалана белергә генә кирәк. Тыңлагыз, укыгыз, яшәгез, сөйләшегез, бөтен мөмкинлек бар.

Комиссия утырышыннан соң Марат Әхмәтов журналистларга: «Мәдәният, Мәгариф министрлыкларын, моны, тегене эшләгез, дип өйрәтү дөрес булмас иде. Без аларга ярдәм итәргә, бергә эшләп, уртак проектлар булдырырга тиеш. Мохитне милли эчтәлек белән тутырырга тырышырга кирәк», – диде.

Сүз кабат җитәкчеләргә әйләнеп кайтты. Дөресрәге, журналистлар Марат Әхмәтовтан түрәләрнең татарча сөйләшүе турында төпченебрәк сорашты. «Күбесе кушкан яки Президент бу мәсьәләгә игътибарлы булганы өчен генә берничә сүз, җөмлә кыстырып сөйләшә. Аны безгә яшәү рәвешенә әйләндерү өчен эшне даими алып бару, һәрдаим аларның үз-үзен тотышына безнең мөнәсәбәтне сиздереп барырга кирәк», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Прокуратура кисәтә

Прокуратура хезмәткәрләре, массакүләм мәгълүмат чараларына һәм социаль челтәрләргә күзәтү ясап, кайбер кибетләрдә шикәр комы булмавын яисә аның бәясе нык кыйммәтләнүен билгеләгән.

Билгеле булганча, республикада шикәр комын ике зур предприятие – «Буа шикәре» һәм «Зәй шикәре» җитештерә. Татарстан прокуратурасы әлеге ике завод җитәкчелеген, шулай ук күпләп сатып алучыларны һәм шикәр комын капларга тутыручы эшмәкәрне шикәр кытлыгына, аның нигезсез кыйммәтләнүенә юл куелмаска тиешлеге турында кисәткән.

Прокуратура материаллары Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсенә алга таба тикшерүгә юлланган. Шикәр комы белән тәэмин итүче башка предприятиеләрне тикшерү дәвам итә. Закон бозу очраклары ачыклангадна, прокуратура тиешле чаралар күрәчәк.

Сату вакыты озайтыла

Татарстанда хәмер белән сәүдә итү вакыты озайтыла. Аны иртәнге 8дән кичке 11гә кадәр сатуны рөхсәт иткән закон үз көченә керде.

Исегезгә төшерәбез: узган атнада Дәүләт Советы депутатларының өчтән ике өлеше спиртлы эчемлекләрне сату вакытын чикләүне бетерүне күздә тоткан закон проектын хуплап тавыш биргән иде. Моңа икътисади дәлилләр китерелде. Шул ук вакытта, Роспотребнадзор идарәсе мәгълүматларына караганда, республикада быел гыйнвар-февраль айларында хәмердән агулануның 97 очрагы теркәлгән. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 3,8 процентка кимрәк.

Чишмәләрне тикшерәләр

Якын араларда республика авылларында су скважиналарын барлау-тикшерү эшләре башланачак. Исемлеккә Арча, Әтнә, Балтач, Югары Ослан, Биектау, Яшел Үзән, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба һәм Теләче районнары кергән. Бу эшнең төп бурычларыннан берсе – авылларның эчәр су белән тәэмин ителешен билгеләү, скважиналарның (чишмәләр) торышын, суның сыйфатын бәяләү, чыганаклар документларының булу-булмавын барлау. Тикшерү нәтиҗәләре буенча сала халкын җир асты чыганакларыннан һәм чишмәләрдән чиста су белән тәэмин итү өчен кирәкле тәкъдимнәр эшләнәчәк. Башка районнарның су чыганакларын 2023–2024 елларда тикшерү күздә тотыла.

Узган елда скважиналар, чишмәләрнең торышын бәяләү буенча пилот проекты сыйфатында, Кайбыч һәм Апас районнарында тикшерүләр үткәрелүен искә төшерик.

Битлекне салырга ашыкмыйлар

Кайбер төбәкләрдә битлектән йөрү таләбе бетерелүгә карамастан, күпләр аны ким дигәндә майга кадәр салмаска ниятли. Rambler&Co агентлыгы үткәргән сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, һәр ун кешенең берсе битлекне җәй башына кадәр киеп йөрмәкче. «Россиянең кайбер төбәкләрендә битлек режимы бетерелсә дә, сораштыруда катнашучыларның 43 проценты аны майга кадәр киеп йөрергә уйлап тора. 40 проценты, битлеккә кабат кире кайтырга мөмкинбез, дип саный. Һәр ун кешенең берсе җәйгә кадәр аны салмаска җыена», – дигән сораштыруны үткәрүчеләр.

Респондентларның 40 проценты саклык чараларын күрүне дәвам итәчәкләрен белдергән. Шуларның күпчелеге (74 проценты) коронавирусның, элеккечә үк, көн кадагында калуын, ләкин башка яңалыкларның аны «күмеп» китә язуын әйткән.

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, пандемия чорында байтак кеше (24 проценты) үзенең сәламәтлегенә җаваплырак карый башлаган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Актуаль тема

Авылларга юл килә

Быел Татарстан авылларында юлсызлык мәсьәләсен хәл итү өчен 574 миллион сум акча тотылачак. Вак таш республика карьерларыннан алыначак, техника – ЕлАЗныкы. Бу хакта транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов хәбәр итте. Җиң сызганып эшкә тотынмакчылар. Башкача мөмкин дә түгел.

Министр яшерми – соңгы вакытта алар үз тарафына Татарстан Президентыннан күп кисәтү алганнар. Рөстәм Миңнеханов министрлыкның еллык коллегиясендә дә аларга зур бурычлар куйган иде. Президент халыктан юлларның начар булуына һәм җәмәгать транспортына карата шикаятьләр күплеген җиткергән иде.

– Быел без 20 районда юл төзү эшләрен башлыйбыз. Юллар бик начар булган өч районга: Биектау, Тукай, Яшел Үзәнгә 50шәр миллион сум акча бирелә. Вак таш белән түшәлгән 1 километр юлның бәясе 5 миллион сумга төшә. Мондый юл биш елга җитә, – диде министр. – Безгә үзебезнең вак ташыбыз, комыбыз кирәк булачак. Татарстанда 36 карьерның сыйфаты тикшерелде. Алар югары маркалы товар бирә ала. Илдәге вазгыять шуны таләп итә – үзебездәге җир байлыкларын кулланырга кирәк.

Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының автомобиль юллары идарәсе җитәкчесе Олег Казеннов та аны куәтләп, бездә чыгучы «400» дип аталган вак таш юл салу өчен менә дигән чимал, диде. «Республиканың бар районнары да юлларны төзү программасында катнашырга теләк белдерде. Үзләрендә карьер булмаганнарга чималны башка районнан китерәчәкбез. Карьерларда чималны узган елга караганда күбрәк итеп чыгару мөмкинлеге бар. Элек эш җитмәсә, хәзер артыгы белән булачак», – диде ул.

Фәрит Хәнифов сүзләренчә, күп кенә авылларга күтәртелгән юллар салыначак. Дөрес, кайларда икәне әлегә билгесез. Күпбалалы гаиләләр өчен җир бүленеп бирелгән бистәләрдә эшләнәсе эшләр тагын да чыгымлырак булачак, анда да юл юк бит. Белгечләр аңлатуынча, авылларга илтүче юлны салу өчен ком һәм вак таш кирәк булачак.

Очрашуда юллар гына түгел, алардан йөрүче транспортлар хакында, дөресрәге, халыкны йөртүчеләр турында да сүз булды. Бу хакта Татарстанның юл һәм транспорт министры урынбасары Тимур Никонов сөйләде. Сер түгел, күп кенә газета укучылардан районнан авылга йөрүче автобуслар сирәк йөри дигән зарлар ишетәбез. Кайберләре атнага бер генә йөри, кайбер маршрутлар бөтенләй бетерелгән. Тимур Никонов автобуслар йөрмәүне үзенчә аңлата.

– Бәяләрнең артуы, техниканың искерүе, пассажирлар аз булу сәбәпле, күбесе тукталды. Министрлык хезмәткәрләре районнарга чыгып, халыкны ташучылар белән күп кенә сөйләшүләр уздырды. Бергәләп киңәшкәч, уртак фикергә килдек. Әлеге вакытта берничә пилот проект буенча эшлибез, – диде ул. – Республиканың дүрт районында: Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск, Яшел Үзәндә халыкны ташу өчен яңа система буенча эшләячәкбез. Әгәр әлеге проект үзенең кирәклеген раслый икән, башка җирләрдә дә кулланачакбыз. Хәзер юл йөрү өчен тариф билгеләү, транспорт оешмаларына килгән зыянны каплау өчен компенсация билгеләү алымнарын уйлыйбыз.

Сүзгә-сүз

Александр ПЕТРОВ, Россия Дәүләт Думасының сәламәтлек саклау комитеты әгъзасы:

Инсулинга бәйле кешеләрнең ун проценты даруханәләргә йөгерде һәм ярты еллык запас туплап куйды. Шушы ыгы-зыгы аркасында пациентларның калган 90 проценты препаратсыз калды. Ләкин бүген Россия җитештерүчеләре халыкның инсулинга мохтаҗлыгын 200 процентка, ягъни ике тапкыр арттырып канәгатьләндерә ала.

(«Парламентская газета»га биргән әңгәмәсеннән)



РОССИЯДӘ – ИҢ ЗУР ХЕЗМӘТ ХАКЛАРЫ

«РИА Рейтинг» агентлыгы Россия төбәкләрендә иң зур хезмәт хакы түләнгән тармакларны ачыклаган.

Урын	Төбәк	Тармак	Уртача хезмәт хакы (мең сум)
1	Сахалин	Казылма байлыклар чыгару	206
2	Мәскәү	Финанс хезмәте күрсәтү	199
3	ЯНАО	Нефть һәм газ чыгару	179
...			
38	**Татарстан**	**Казылма байлыклар чыгару**	**62**
...			
83	Калмыкия	Дәүләт хезмәте	39
84	Мордовия	Дәүләт хезмәте	39
85	Иваново өлкәсе	Дәүләт хезмәте	39



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БИШЕНЧЕ ПАКЕТ: НЕФТЬТӘН БАШКА БУЛАМЫ?

Евросоюз Россиягә каршы санкцияләрнең бишенче пакетын әвәләү белән мавыга. Европадагы радикаллар Россия нефтен һәм газын сатып алуга эмбарго кертүне таләп итә. Әмма дә ләкин бу бер селтәүдә генә хәл ителә торган мәсьәлә түгел, чөнки Себер углеводородларыннан баш тарту энергетик коллапс китереп чыгарырга мөмкин.

Мәскәү махсус хәрби операция башлар алдыннан нәкъ менә шуңа исәп тотты һәм катгый санкцияләр булмас дип өметләнде. «Кара алтын»ның бүгенге бәясе кот очарлык ук түгел ул үзе. Искә төшерик: 2008 елның көзендә җир мае баррельгә 147 доллар бәя сорый башлаган иде. Глобаль кризис адымнары ул бәяне кисәк түбәнгә – 30 долларга кадәр ыргытты. 2014 елда, Кырым эпопеясенә кадәр дә нефть 117 долларга йөрде. Бүген 100–116 доллар чикләрендә тирбәлә. Россия өчен бик яхшы бәя, Көнбатыш өчен дә үтерерлек түгел. Мәскәү белән бил алышучы каршы як углеводородлар бәясен төшерергә омтыла һәм озак сроклы перспективада Мәскәү белән бу өлкәдә хезмәттәшлекне бөтенләй туктатырга тели. Хәзерге вакытта шартлар Россия файдасына. Иран һәм Венесуэла якындагы көннәрдә генә углеводородлар экспортын арттыра алмыйлар. Бу берничә көн, хәтта ай эше генә түгел. Согуд Корольлеге һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дә арттырырга ашыкмыйлар. Дүшәмбе көнне согудләрнең Тышкы эшләр министрлыгы нефть дефициты өчен җаваплылыкны үз иле өстеннән төшерде, Йәмән гыйсъянчыларының һөҗүмнәре шартларында экспортны арттыра алмауларын әйтте. Гарәпләр Көнбатышның гыйсъянчыларны җиңеп бирүен таләп итә, кыскасы.

АКШның сланец нефте чыгаручы компанияләре никтер «кара алтын» чыгаруны арттырмыйлар. Моңа Байден үткәргән икътисад сәясәте гаепле дип беләм. Хәтерсез Президент нефтьчеләргә Трамп биргән барлык өстенлекләрне алып бетерде һәм аларны салымнар белән богаулап куйды. Менә шундый шартларга карамастан, җир мае бәясе әлегә чагыштырмача юньле тора һәм хәл түзәрлек. Әмма Россияне бу сагайтырга тиеш. Бүген югары торган бәя иртәгә түбәнгә дә оча ала. Аннан соң бер нәрсәне истә тотарга кирәк: Россия нефте дисконт белән, ягъни 25–30 процентка түбәнрәк бәядән сатыла бүген. Әйтик, Һиндстанга «кара алтын»ны арзанга сата, транспортлау һәм иминиятләштерү чыгымнарын да Мәскәү күтәрә. Сәүдә дә резерв валюталарында түгел, ә рупияләрдә алып барыла.

Көнбатышта нефть бәясен төшерүнең башка чараларын да карыйлар. Халыкара энергетика агентлыгы халыкка ягулык тотуны киметү ысулларын тәкъдим итә. Мөмкин булганда, кимендә атнага өч көн өйдән торып эшләү, каршерингны үстерү, ягъни автомобильне прокатка гына алып тору, магистральләрдә тизлек режимын чикләү, ял көннәрендә шәһәрләрдә автомобильдән файдаланмау, җәмәгать транспортына бәяләрне төшерү, велосипед һәм самокатларда йөрү, командировкалар урынына видеоэлемтәдән файдалану, очкычлар урынына поездларга утыру… Шул чараларның барысын да куллану Россия нефтенә бәйлелекне 40 процентка киметәчәк икән. Кризис шартларында россиялеләр өчен дә бик кыйммәтле киңәшләр болар.

Әлегә бишенче пакет эмбаргодан башка гына кабул ителер төсле. Венгрия аеруча каты каршы чыга аңа, Германия дә хуплап бетерми.

Россиядә

НЕФТЬ САТМАСАК, ОБЛИГАЦИЯ САТАРБЫЗ

«Кара алтын» экспорты Россия өчен гадәттән тыш әһәмиятле өлкә бүген. СССРны ничек екканнары хәтердә әле. Углеводородлар бәясе кискен түбән төшү импорт товарларга кытлык китереп чыгарды, сумга ышаныч бетте…

Көнбатыш тагын бер тапкыр шушы уен картасын файдаланырга тырыша, һәм аек күз белән карыйк: аның моңа мөмкинлекләре җитәрлек. Үткән ел ахырында Европа көнгә 3 миллион баррель Россия нефтен һәм 1,5 миллион баррель нефть продуктларын сатып алган. Россия чыгарган нефтьнең 20 проценты Көнбатышка киткән дигән сүз бу. Җиң сызганып тотынсалар, бер-ике елда европалылар миллион баррельләрдән тулысынча баш тарта ала. Белгечләр быел ук апрель – май айларында Көнбатыш кулланучыларының бойкоты нәтиҗәсендә Россиядә «кара алтын» чыгару бер тәүлеккә өч миллион баррельгә кимеячәк, диләр. Бу 25 процентка тиң. Европа баш тарткан нефтьнең әлегә бары тик 5–10 процентын гына Көнчыгышка юнәлтеп булачак. Аңлашыла инде: Россия бюджеты өчен аяктан егарлык һөҗүм була ала бу, чөнки бюджет «күлмәге» нефть акчасына үлчәп тегелә. Әлегә бюджет гадәттән тыш зур табыштан гына колак какты, акча җитәрлек. Моңарчы җиткәннән артык акчаны офшорларга озатып бардык бит инде, үзебезнекен җитештерү өчен тотмадык диярлек.

Тик төшенкелеккә бирелеп, елап утырып булмый. Федераль хөкүмәттә әлегә оптимизм җитәрлек, читләргә әҗәткә биреп торырлык. Казнаны тулыландыруның бер юлы – облигацияләр, ягъни әҗәт кәгазьләре сату. Бюджет профициты шартларында да (бу юллар авторы карашынча, бер дә кирәкмәгәндә дә) соңыннан процент белән кайтарып бирү өчен байтак облигация сатылды, аны чит ил спекулянтлары да алды. Хәзер элек сатылган облигацияләрне түләргә кирәк. Бездә әҗәтне әҗәт алып түләү гадәткә кергән.

Бу атнада Үзәк банк бик сак кына биржа сәүдәсен башлап җибәрде. Әлегә компанияләрнең кыйммәтле кәгазьләре сатылмый, облигацияләр генә сәүдәгә куелды. Алар ун процент тирәсе очсызланды. Белгечләр бу арзанаюны начар түгел дип саный. Бөтенләй чүп бәягә кадәр төшү ихтималы да бар иде бит. Бездә сәүдә схемасы шундый бит: Үзәк банк акча басып банкларга өләшә дә, банклар хөкүмәт облигацияләрен сатып алалар. Элек сатып алган облигацияләрнең бәясе төшү – банклар өчен югалту ул. Бөтен оптимизм шуңа гына нигезләнгән: югалту ун процент кына, күбрәк тә була ала иде.

Әлегә вазгыять шундый. Облигация сату инфляция югалтуларын капламый. Иртәгесе көн сәүдәсе турында берни дә әйтеп булмый.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Казан авиация заводында елына ун Ту-214 очкычы җитештерергә җыеналар. Бу хакта Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Юрий Борисов Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән сөйләште.

tatarstan.ru

С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводында Юрий Борисов белән Рөстәм Миңнеханов җыю цехларын карадылар, ракета йөртүче Ту-160М бомбардировщикларын кабат җитештерү программасының гамәлгә ашыру барышы белән таныштылар. Юрий Борисов Ту-160 очкычларын җитештерү эшен уңай бәяләде. «Казан безнең хәрби-һава көчләре өчен стратегик авиацияне төп җитештерүче булып санала. Монда бар да план буенча бара. Быел бер яңартылган һәм бер яңа Ту-160 очкычларын күтәбез», – диде ул.

Очрашуда Ту-214 пассажир очкычларын күбрәк итеп җитештерү хакында да сөйләштеләр. Юрий Борисов фикеренчә, киләчәктә Казан авиация заводы елына ким дигәндә мондый 10 очкыч ясап чыгара ала. «Бирегә шул хакта сөйләшергә килдек тә инде. Әлегә Ту-214 махсус очу отряды өчен берәмләп кенә җитештерелә», – диде вице-премьер.

Юрий Борисов сүзләренчә, хәзер «Аэрофлот», «Ред Вингс» авиакомпанияләренең Ту-214 очкычларыннан файдалану мөмкинлеге карала. Очкычның моңа кадәр чит илдә ясалган җиһазларын бер ел эчендә үзебездә җитештерә башлау нияте бар.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Казан авиация заводының Хөкүмәт билгеләгән бурычларны үтәргә көче җитәрлек. «Җитештерүне 10 очкыч чыгарырлык итеп яңартырга һәм әзерләргә кирәк. Безнең бурыч – кадрлар, белгечләр, инженерлар, эшчеләр әзерләү. Бу бурычны үти алачакбыз», – диде ул.

ЮГАЛМА, МАШИНА

Машинага аеруча күз-колак булыр чак! Белгечләр «тимер ат»ы булганнарны әнә шулай дип кисәтә. Ник дигәндә, килеп туган вазгыять аркасында якын арада илдә машина урлау очраклары икеләтә артырга мөмкин дип кисәтә алар. Депутатлар исә машина урлауны авыр җинаятьләр рәтенә кертергә тәкъдим итә.

«Машина җитештерүче күп кенә зур халыкара компанияләр бездә эшләми башлады. Шул рәвешле хәзер машиналарга гына түгел, запчастьларга да кытлык башлануы ихтимал. Бу исә машина урлау очраклары да артырга мөмкин дигән сүз. Аларны, нигездә, запчастьларын «чүпләү» өчен урлаячаклар», – дип фаразлый «Бердәм Россия» партиясеннән Санкт-Петербург Закон чыгару Җыены депутаты Павел Крупник. Шуңа күрә ул канупнарны кырысрак итәргә тәкъдим итә. Аның фикеренчә, машина урлау авыр җинаять буларак бәяләнергә тиеш.

Иминият тармагы вәкилләре дә шул ук фикердә. Илкүләм иминиятчеләр берлеге вәкиле Михаил Порватов, угрылар кулына иң беренчеләрдән булып чит ил машиналары эләгәчәк, дип фаразлый. Әлегә аларга яраклы запчастьларны кыйммәтрәк бәягә булса да табарга мөмкин. Киләчәктә исә хәлләр тагын да катлауланырга мөмкин. Ник дигәндә, хәзер алар читтән кертелми. «Тәҗрибә күрсәткәнчә, мондый чакта җинаятьләр саны бермә-бер арта. Әлегә складларда запчастьлар бар. Әмма якын арада алары да бетәчәк. Бу детальләрне табуның яңа юллары ачылмый торып, аларны тиз генә кулга төшереп булмаячак», – дип фикер йөртә Порватов.

«Альфа-иминиятләштерү» оешмасыннан алынган мәгълүматларга караганда, машина угрылары пандемия чорында аеруча активлашкан. Ул чорда алар, нигездә, Land Rover Freelander, Toyota Land Cruiser, Toyota Land Cruiser Prado машиналарын чәлдергән. Узган ел угрылар күбрәк Кореяда җитештерелгән машиналарга өстенлек биргән. Рәсми мәгълүматларга караганда, узган елның тугыз аенда Россиядә машина урлау очраклары, алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда – 14,8, запчастьлар урлау 25,4 процентка кимрәк булган.

«Автостат» аналитика үзәге белгече Азат Тимерханов, яңа закон гамәлгә керә калса, машина урлау очраклары азмы-күпме кимер, дигән фикердә.

– Ләкин бу очракта машина хуҗалары күбрәк үзенә ышанырга тиеш. Угрылардан саклану өчен машинаны гаражда калдыру хәерле. Юкса соңгы арада күп кенә машина йөртүчеләр ирекккә чыкты. Төнгә машинаны кайда буш урын тапса, шунда калдырып китә. Гараж булмаса, аны түләүле машина кую урынына куярга кирәк. Сигнализациядән тыш машинада урлаудан саклый торган механик чаралар булса да яхшы, – ди белгеч.

Россия автомобильчеләр федерациясенең Татарстан буенча бүлеге җитәкчесе Рамил Хәйруллин яңарак машиналарны иминиятләштерергә дә киңәш итә. «Тимер ат»ның кайда йөрүен телефон аша күзәтеп торырга мөмкинлек бирүче JPS-трейкер дигән җиһаз да һәр машинада булырга тиеш дигән фикердә ул.

– Болай дәвам итсә, 90 нчы еллардагы хәлләр кабатланырга мөмкин. Үткән-сүткәндә кешеләрнең машинадагы тәрәзә чистарткычларга кадәр салдырып киткән вакытларны күбебез хәтерлидер, – ди белгеч. – Нәрсәне алып була, шуңа кул сузачаклар. Иң беренче чиратта, арендага алына торган каршеринг машиналары зыян күрер дип уйлыйм. Ул бит беркемнең дә милке түгел. Аларны урлап ук китәрләр дип уйламыйм. Ә менә запчастьларын сүтеп бетерүләре бик мөмкин. Шуңа күрә законны кабул итү генә түгел, аның эшләве дә кирәк. Полиция хезмәткәрләре угрыларны тиз арада эзенә төшеп, җәзага тарта алса гына бу законның нәтиҗәсе булачак.

Илкүләм иминиятчеләр берлеге күптән түгел урлауга авырдан һәм, киресенчә, җиңел бирешә торган машиналар исемлеген төзегән. Угрылардан иң аз якланганнар исемлегенә Lada Granta, Lada Vesta, Renault Logan, Renault Sandero машиналары кергән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, узган ел республикада авто һәм мототранспорт урлауның 79 очрагы теркәлгән. Мондый җинаятьләрнең 57 проценты ачыла. Былтыр республикада транспортны рөхсәтсез алып китүнең (угон) 323 очрагы теркәлгән. Мондый җинаятьләрнең 93 проценты фаш ителә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«Татар-информ»

Казансу чистарачак

Экология

Татарстанда елгаларның һәм сулыкларның экологик торышын яхшырту буенча сынау проекты эшли башлый. Беренче эш итеп экологлар Казансу елгасын чистарта башламакчылар. Әлеге эш Рус география җәмгыяте, Россия Фәннәр академиясенең әйдәп баручы институтлары һәм башка фәнни оешмалар белән берлектә тормышка ашырылачак.

Казансудагы су сыйфаты өч ел эчендә яхшырырга тиеш. Бу хакта журналистларга Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Айрат Шиһапов сөйләде.

– Әлеге проект ике өлештән тора, – диде ул. – Башта без елганың пычрану сәбәпләрен ачыклаячакбыз. Казансуның составы турында белешмә җыябыз. Елгага начар йогынты ясаучы сәбәпләрне ачыклаячакбыз. Су нигә пычрана? Чистарту корылмалары җитмиме? Елгага аккан сулар нәтиҗәсеме бу, әллә инде яңгыр сулары төшәме, читтән авыл хуҗалыгы калдыклары агып ятамы – барысын да белергә кирәк. Икенче этапта проектка әйдәп баручы институтлар һәм фәнни оешмалар кушылачак. Алар аерым тикшеренүләр уздырачак һәм суның торышын яхшырту буенча эшләячәк. Шуннан чыгып, без елганы пычратмас өчен чаралар күрә башлаячакбыз. Яр буена агачлар утыртырга, биологик чистарту корылмалары төзергә кирәк булачак. Елгага начар сулар агуны туктату чарасын күрәчәкбез. Уңышлы дип табылса, бу проектны Татарстан һәм Россиянең башка су объектларында да кулланырга мөмкин булачак.

Елгадагы су сыйфатын Рус география җәмгыятенең Татарстандагы төбәк оешмасы хезмәткәрләре тикшерәчәк. Кар эреп беткәч, алар яр буйларын күзәтәчәкләр. Суның чисталыгы да контрольдә булачак. Экологлар 30 мартта ташу китәр дип фаразлап торалар. Шуннан соң ике атна дәвамында Казансуның суын көн саен тикшерергә алачаклар. Су пробалары алыначак 15 урын билгеле инде. Кирәк булган саен аларның саны да артачак.

Рус география җәмгыятенең Татарстандагы төбәк оешмасы җитәкчесе урынбасары Андрей Агарков: «Берничә төркемгә бүленеп эшләячәкбез. Без суның пычранган урыннарын караячакбыз. Су саклау зоналарына якын урнашкан ягулык станцияләрен, суга пычрак агызып яткан авыл хуҗалыгы җирләрен ачыклап, аларны теркәп барачакбыз. Безнең максат – тикшеренү, игътибар таләп итә торган нокталарны күрү, аларны табу һәм фотога төшерү, картада билгеләп үтү. Соңыннан бу мәгълүматларны министрлыкка тапшырачакбыз», – диде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Вазгыять

Кибетләрдәге бу ыгы-зыгылар башланганчы ук инде Балтачтагы бер кибеткә керсәм, өлкән яшьтәге бер апа 90 сумнан ниндидер (кайсыдыр илдән кайткан) бәрәңге сайлап маташа. Бәрәңгеләре уртакул гына, кыяфәте дә әллә кем түгел. Түзмәдем: «Апа, бу кадәр кыйммәткә бу бәрәңгеләрне алганчы, Салавыч колхозы («Татарстан» хуҗалыгы, өлкән кеше аңласын өчен авыл исеме белән әйттем) 30 сумга эре бәрәңгеләр сата бит. Атна саен һәр шимбәдә саталар, белдерүләре чыгып тора», – дидем.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АВЫЛ НИЧЕК ЯШИ?

«Анда кадәр төшәргә (сигез километр) машинасы кирәк бит әле», – дисә дә, ул уйлана калды. Алгандырмы, белмим, Салавычка төшеп өлгергәндерме, бу атнада әлеге хуҗалыкның белдерүеннән инде «эре бәрәңге сатабыз» дигән өлеше төшеп калган булып чыкты. Орлыклык бәрәңгене килограммын – 17, малга ашатыр өчен вак бәрәңгене 6 сумнан сатабыз, сатуда эре бәрәңге юк, дигәннәр. Бу белдерүгә игътибар да итмәс идем, әмма соңга көннәрдәге вазгыять кешеләрне уйландыра башлады. Эшләп азапланасы да юк, барысы кибеттә бар, дип, җиңелрәк яшәү рәвешенә күчеп диярлек беткән авыл халкы да: «Болай булса, бәрәңге җирләрен арттырмыйча булмас», – дип сөйләшә башлады (шул сәбәпле, мин әйткән хуҗалыктан утырту бәрәңгеләре сатып алучылар да арткан). Әй, һаман бәрәңге генә ашап тормабыз әле, җитә ул, дип, бәрәңге бакчаларын кечерәйтеп бетергән идек шул. Хәер, әлегә бу кадәресе дә сөйләшү генә. Алда әле башланмаган бер ай бар, сала кешесенең фикерен үзгәртергә күп кирәкми.

Әнә бит, үткән ел корылык булып, печән-салам, ашлык бәяләре шактый кыйммәтләнгәч, «Иии, бу бәягә корма сатып алып, мал асрап булмас, сыерларны, бозауларны киметәсе булыр», – дигәннәр иде, сөткә-иткә бәяләр әллә ни сизелерлек тә артмады, ел буена җитәрлек азыгын да туплады, мал-туарын да киметмәделәр. Әле алай гына да түгел, кыш буе буаз сыер сатып алам дигән белдерүләр дә күренгәләп торды. Соңгы вакыттагы ыгы-зыгылар башлангач, ышанам, бик күпләр: «Әле ярый терлекләрнең санын киметмәгәнбез», – дип тагын бер кат шөкер иткәндер. Каланыкылардан бер өстенлеге инде бу авыл халкының. Ул нинди генә катлаулы вазгыять булса да, ач булмабыз, ите-мае, сөте үзебезнеке, дип шөкер итәргә күнеккән.

Шәһәрләрдә халык талашып-тарткалашып шикәр комы, он, башка төр ашамлыклар, су буе чиратлар тора-тора, көнкүреш товарлары, гигиена әйберләре җыйганда да авыл ничектер бу әйберләргә тынычрак карады шикелле. Район үзәге белән дә авыллардагы вазгыять күпкә аерылды. Бәлки мәгълүматның күбесенчә берьяклы булуы да үз эшен эшләгәндер. Кечерәк авыл кибетләрендә әле дә кырылып нәрсәдер алалар димәс идем. Бездә, мәсәлән, шәхси эшмәкәрнең кечкенә генә бер кибете эшли. Атнага ике тапкыр товар кайтып тора. Авыл халкы кайтканнан-кайтканга алып күнеккән. Бу көннәрдә берничә тапкыр барып та әллә ни аерма күрмәдем. Бушаган киштәләр юк. Элек кайтып калганнарын элеккечә алганнар, хәзер кайтканнарын яңа бәядән алалар. Мисалга, соңгы көннәрдә бер капчык шикәр комы кайткан булган, килограммын йөз сумнан да берәр-икешәр килограммлап алалар икән. Тавышланып, ник алай да ник болай, диюче булмаган.

Кыйммәт булса булсын, булып торсын – авыл халкы ничектер шушындый фикердә. «Бөтен нәрсәгә бәяләр артты, чебешләрнең дә бәясен арттырмый хәл юк, сораучыларыбыз кимемәсме икән дигән идек, шөкер, заявкалар бик күп, – ди үзләренең инкубаторы булган Фирая апа да. – Бөтен кеше, эшләгез генә, ди. Башка елларны да кош-кортны бик күпләп алалар иде. Бездә халык тырыш бит, күпләп асрыйлар, әле һәркайсын берничә партия алып үстерүчеләр дә күп».

Бәлки нәкъ тә менә авылда хезмәт куеп яшәгәндә ач булмабыз дигән ышаныч кешеләргә ниндидер тынычлык бирә торгандыр. Шук вакытта үткән елларда мондыйрак хәлләрдән гыйбрәтләр алдык бит инде, дип, бәяләр артуга, кытлыкларга исе китмәүчеләр дә бар. Андыйлар, бәяләр барыбер кимер, дип өметләнә.

«Бер елны үләм-бетәм дип тоз җыйдык инде, әллә нинди кыйммәт бәяләргә алдык. Озак та тормады, тозга бәя төште, кайтарып та тутырдылар, – ди авылдашым N. апа. – Күпләп запас алырга уемда да юк».

«Запас белән алып өйрәнмәгән идек, өйдә бер салырлык шикәр комы калган иде, соңгы пачка тозны башлаган идек», – диючеләр дә юк түгел. Авыл халкының да күпчелеге элекке кебек капчык-капчык он, шикәр комы, тоз һәм башкасын запасламый гына, кибеттә көндәлек барысы да барлыкка күнеккән иде шул инде. Шул ук вакытта калага баручыларга әллә юри, әллә чынлап, очсыз бәядән ашамлыклар алып кайтырга кушучылар да, акча алышына икән (дефолт дип сөйләшми авылныкылар) дигән сүзләргә дә, байлар кайгырсын, дип исе китмәгән кыяфәт чыгаручылар да, һәммәсенә битарафлар да бар. Һәркем үзенчә фикерле, үзенчә яши. Иң мөһиме, бөтенесе вакытлыча гына, хәзер барысы үз урынына кайта дигән өметләре аклансын да, шәһәрдәге матавыклар килеп җиткәнче, вазгыять үзе үзгәрсен иде…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КҮПКЫРЛЫ ИМАМ

Буа районының Иске Суыксу авылының мәчете яшен сугудан тулысынча янып беткәч, әлеге нигезне яңадан торгызырга булды Линур хәзрәт САБИРҖАНОВ. Аның өчен бик зур сынау була бу.

Бәйге

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Кара җирдән зур мәчет

Бу эшне ул Аллаһ ярдәме белән ике ел эчендә башкарып чыкты. Ул вакытта мөфти булып эшләгән Госман хәзрәт Исхакый да ярдәм итте, район җитәкчелеге дә кире борып чыгармады. Төзелешкә матди ярдәм булгач, фундаментын казудан башлап, соңгы детальгә – манара урнаштырганчыга кадәр үзе мәшәкатьләнде. Билгеле, моның өчен аңа Казан, Ульяновск шәһәрләрендәге төзелеш материаллары җитештерә торган завод юлларын күп таптарга туры килде. Авыл халкы гаҗәпләнде дә, сөенде дә. Ходай йорты ике катлы итеп төзелде, аның ишекләрен ачкан көннән бүгенгә кадәр биредә кеше өзелгәне юк.

Халык аны «Линур мәчете» дип атарга кирәк, дигән тәкъдим белән берничә тапкыр чыкты. Тик хәзрәт каршы килде, мактаганны, изге эшләрне кычкырып йөргәнне яратмый, гади итеп «Үзәк мәчете» дип исем куйдырды.

– Иске Суыксу – Буа районында иң зур авыл. Аның биш мәчете генә бар. Һәрберсендә берничә дистә мөселман кардәшләр намазга йөри. Алар арасында яшьләр, балалар күп. Бу сөендерә. Соңгы вакытта авылда тагын бер мәчет салдырырга йөриләр дип ишеттем. Хәлемнән килгәнчә ярдәм кулын сузарга әзер, – дип сөйләде Линур хәзрәт…

Ходайга хезмәт итәргә кечкенәдән хыялланган ул. Ике әби белән үскән малай 7 яшендә 13 доганы яттан белә торган була. Мәктәпне тәмамлап, Казан педагогика университетына укырга килгәч тә, аны дингә якынаю уе ташламый. Ә аңа төпләп керешү өчен сәбәп уйламаганда-көтмәгәндә була. Студент вакытта бераз акча эшләү уе белән төрле эшләргә алына – Камал театрында декорацияләр ташып йөргәндә, Казанның яңа гына ачылган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе хезмәткәрләре белән очраша. Аралаша торгач, алар Линурның төпле, сүзен үлчәп сөйли торган егет икәнен, дин юлына басарга теләге зур булуын аңлыйлар. Шуннан ул мәдрәсәгә укырга чакыру ала. Беррәттән университетны да ташламый егет, икесен дә яхшы билгеләргә тәмамлый.

Аннан Сүриядә уку мөмкинлеге туа. Линур, ерак сәфәр булса да, ике дә уйламый, ризалаша. Укуын тәмамлагач, өлкән яшьтәге әти-әнисен уйлап, туган ягы Иске Суыксу авылына кайта. Биредә дә инициативалы, белемле яшь хәзрәтне тиз күреп алалар – озак та үтми, районның имам-мөхтәсибе итеп сайлыйлар. Берничә ел дәвамында ул әлеге җаваплы вазыйфаны биләсә дә, үзе салдырган мәчеттәге мәхәллә эшен ташламый. Хәзер дә мәчет эшләрен җиренә җиткереп эшли. Һәр шимбә саен гыйбадәт кылганнан соң сарык чалалар, хәләл җефете Альмира шулпа пешерә, мәчеткә йөрүчеләрне, мохтаҗларны, балаларны сыйлый.



Балалар дигәннән, Иске Суыксу мәктәбе укучыларына булышып торуны ул үзенең гадәтенә кертә. Узган елларны сыйныфка интерактив такта, спорт киемнәре, инвентарьлар алып бирде.

– Сабыйлар сөенгәнне күргәч, күңелемә рәхәт. Ходай разыйлардан кылсын, кабул итсен, – ди хәзрәт. Мондый сүзләрне ул кылган һәр изге эшеннән соң әйтә. Мәсәлән, Иске Суыксу һәм Буа шәһәренең азык-төлек, ипи кибетләре сатучыларына ул болай ди: «Әгәр дә тиеннәрне санап торучы мохтаҗларны күрсәгез, бирегез, кызганмагыз товарны, ә алар биреп бетермәгән сумманы бурыч дәфтәренә минем исемгә язып куегыз. Барыбер кибеттә еш булам, үзем түләп чыгам», – ди.

Әлбәттә, Линур хәзрәт Сабирҗанов турында тагын бик күпләрне язып булыр иде. Мәсәлән, аның ун ел буе хаҗ кылганда татарстанлыларга куратор булуы һәм башкалар.

Сирәк һөнәрле имам

Иске Суыксу авылында яшәүче Линур хәзрәт Сабирҗанов сирәк һөнәр үзләштергән. Ул чалма ясый. Аны әзерләү барышы белән без дә танышып кайттык.

Линур хәзрәт, бу шөгыльгә чарасызлыктан тотындым, ди.

– Мәчеттә чалма киеп, гыйбадәт кыласым килде, тик таба алмадым. Шуннан үземнең ясап карыйсы килде. Татарстанның элеккеге баш казые Габделхак хәзрәт Саматовның моңа оста икәнен белә идем. Бу эшкә мине дә өйрәтүен барып ялындым. Ул ризалашты. Хәзер без, чалма ясаучылар, Россиядә дә берничә кеше генә, – диде ул.

Аннан аны ясау серләрен безгә дә сөйләде. Алдан каты кәгазьдән түбәтәй формасында чалманың каркасы эшләнә. Аның өчен махсус 1 миллиметр калынлыктагы каты кәгазь алына. Аннан «түбәтәй»нең ян-яклары киселә. Аның тәбәнәк дигәне – 10–12, ә биеге – 12–14 сантиметр озынлыкта, аннан түбәдәге түгәрәк киселә, аны берничә урыннан тишәләр, бу баш сулыш алсын өчен кирәк. Аннан әлеге элементларны түбәтәй формасында ябыштырып тоташтыралар. Эченә кара материал ябыштыралар. Каркас әзер. Әгәр баш киеме ярамаса, хәзрәтнең аны зурайта торган станогы да бар. Чалманы чорнаганчы, түбәсенә бәрхет материал ябыштырылып калдырыла.

– Каркасны һәрбер кеше эшли ала. Ә менә чалманы дөрес иттереп чорнау – бик четерекле эш. Аны мин үзем дә озак вакыт өйрәндем. Хәзер инде күз йомып та чорный алам, – диде хәзрәт.

Чорнау өчен 1 метр киңлектәге, 10 метр озынлыктагы медицина марлясы алына. Марляны кимрәк тотсаң, чалма ап-ак булмый. Аны пычратмый чорнау – үзе бер осталык. Марля күп куллануның тагын бер файдалы ягы да бар – әгәр дә чалманың хуҗасы вафат булса, аны сүтеп, кәфенлеккә кулланырга мөмкин. Баш киеменең иң авыр өлеше – бер линиягә туры китереп чорнау. Әгәр дә кабул ителгән инструкциядән читкә китсәң икән, чалма матур һәм зәвыклы булмый, ди Линур хәзрәт. Бер чалманы ясап чыгар өчен 1–2 көн вакыт китә.

– Чалма – кадерле һәм затлы бүләк. Мин аны имамнарга, дусларымның әтиләренә юбилейга бүләк итәм. Рәхмәт әйтеп алалар. Шулай ук читтә яшәүче остазларыма да җибәрәм. Татарстанның мөселманнар корылтаена мөфти Камил Сәмигуллинга да чалма алып килдем, – диде Линур хәзрәт.

Эшләгән эшләре дә, киләчәккә планнары да җитәрлек, иншалла, башкарып чыгарга гына язсын!

Әлфинур ЙОСЫПОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча муниципаль мәгариф оешмаларында белем алучыларның һәм хосусый гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның туклануын оештыру чараларын өстәмә финанс белән тәэмин итәргә, балаларга өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә, шул исәптән балаларга өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәм хосусый белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итәргә, муниципаль мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган урта гомуми белемнең дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программасы чикләрендә эшче һөнәрләренә, хезмәткәрләр вазыйфаларына һөнәри әзерлек программалары буенча һөнәргә өйрәтүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә, Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган, дәүләт аккредитациясе булган урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программасы, урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары чикләрендә эшче һөнәрләренә, хезмәткәрләр вазыйфаларына һөнәри әзерлек программалары буенча һөнәргә өйрәтүне оештырырга хокуклы.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 март
№ 8-ТРЗ

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш); 2016, № 1 – 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), 2020, № 77 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 март
№ 9-ТРЗ

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенең, шулай ук, әгәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторлары вазыйфалары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый акты белән муниципаль вазыйфаларга кертелгән булса, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарының һәм аудиторларының» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенең, рәисе урынбасарының һәм аудиторларының» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 6 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 15 статьяның 2^1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

4) 1 нче кушымтада:

а) 3 бүлекнең 2 пунктындагы өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 7 бүлекнең 2 пунктындагы алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 2 нче кушымтаның 6 пунктындагы ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 март
№ 10-ТРЗ

Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2022 елның 16 мартында кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексының 284^3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган региональ инвестиция проектларында (алга таба – региональ инвестиция проектлары) катнашучылар өчен оешмалар табышына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым буенча салым ставкасын билгели.

2. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексының 3^3 бүлеге нигезендә региональ инвестиция проектларына өстәмә таләпне, оешманы региональ инвестиция проектларында катнашучылар реестрына (алга таба – реестр) кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү тәртибен, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итү тәртибен һәм шартларын билгели.

2 статья. **Оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы**

Региональ инвестиция проектларында катнашучылар өчен оешмалар табышына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым буенча салым ставкасы, салым исәбе мәгълүматлары нигезендә региональ инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән товарларны сатудан беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм оешмалар табышына салым буенча 20 процент күләмендәге салым ставкасыннан чыгып исәпләнгән оешмалар табышына салым суммасы һәм оешмалар табышына салым буенча әлеге статьяда һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 1^5 пунктында билгеләнгән салым ставкаларын кулланып исәпләнгән оешмалар табышына салым суммасы арасындагы аерма булган хисап (салым) чоры белән тәмамлап, 10 процент күләмендә билгеләнә, бу аерма әлеге хисап (салым) чорларында үсеп килүче нәтиҗә белән билгеләнә һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында башкарылган капитал салуларның Россия Федерациясе Салым кодексының 284^3 статьясындагы 8 пункты нигезендә билгеләнә торган күләменә тигез булган күләмне тәшкил итә.

3 статья. **Региональ инвестиция проектларына өстәмә таләп**

Россия Федерациясе Салым кодексының 25^8 статьясында билгеләнгән таләпләргә өстәмә рәвештә региональ инвестиция проекты «Электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау турында һәм электр энергиясен һәм егәрлеген күпләп сату базарының эшләвен оештыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерация объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча инвестиция проектлары исемлегенә кертелергә тиеш.

4 статья. **Оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү тәртибе, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итү тәртибе һәм шартлары**

1. Оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү турында карарлар кабул итү, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 25^{10} – 25^{12} статьяларында каралган башка вәкаләтләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең икътисадый үсеш өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Реестрга кертү өчен оешма вәкаләтле органга, Россия Федерациясе Салым кодексының 25^{11} статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, реестрга кертү турында ирекле рәвештә төзелгән гариза (алга таба – гариза) җибәрә.

3. Вәкаләтле орган гариза һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 25^{11} статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып өч эш көне эчендә оешмага гаризаны карауга алу яисә, Россия Федерациясе Салым кодексының 25^{11} статьясындагы 1 пунктының 1, 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, гаризаны карауга алудан баш тарту турында карар җибәрә.

4. Оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан оешмага гаризаны карауга алу хакында карар җибәргән көннән алып 30 көн эчендә кабул ителә.

5. Россия Федерациясе Салым кодексында һәм әлеге Законда региональ инвестиция проектларына карата билгеләнгән таләпләрне үтәмәү оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез була.

6. Вәкаләтле орган оешманы реестрга кертү яисә оешманы реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә оешмага тиешле карар җибәрә.

7. Реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү турындагы карар, Россия Федерациясе Салым кодексында һәм әлеге Законда билгеләнгән, региональ инвестиция проектларына һәм (яисә) аларда катнашучыларга карата куела торган таләпләрне үтәү шарты белән, инвестиция декларациясенә региональ инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларына кагылышлы үзгәрешләр кертелгән очракта, вәкаләтле орган тарафыннан ул инвестиция декларациясенә үзгәрешләр кертү хакында карар кабул иткән көннән алып 10 көн эчендә кабул ителә.

8. Инвестиция декларациясенә региональ инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларына кагылышлы үзгәрешләрне кертү вәкаләтле орган тарафыннан региональ инвестиция проектында катнашучының ирекле рәвештә төзелгән, мондый үзгәрешләрне кертү зарурлыгын нигезләве булган гаризасы нигезендә оешманы реестрга кертү өчен әлеге статьяда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Вәкаләтле орган инвестиция декларациясенә региональ инвестиция проектында катнашучының үзгәрешләрен кертүдән Россия Федерациясе Салым кодексының 25^{12} статьясындагы 3 пунктында каралган нигезләр буенча баш тарта.

10. Вәкаләтле орган реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү яисә реестрга үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә региональ инвестиция проектында катнашучыга тиешле карар җибәрә.

11. Оешманы реестрга кертү, реестрга региональ инвестиция проектында катнашучы статусын туктатуга бәйле булмаган үзгәрешләр кертү турындагы карарлар, шулай ук башка кирәкле белешмәләр вәкаләтле орган тарафыннан электрон рәвештә федераль башкарма хакимиятнең салымнар һәм җыемнар өлкәсендәге контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле органына тиешле карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очрактан тыш, 2029 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә була.

2. Россия Федерациясе Салым кодексының 25^8 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасындагы икенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган региональ инвестиция проектларында катнашучылар әлеге Законның 2 статьясында билгеләнгән оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану хокукын 2027 елның 1 гыйнварыннан башлап югалталар.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 21 март
№ 11-ТРЗ

Белдерү

2023 елда Татарстан Республикасы территориясендәге капиталь төзелеш объектларына дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү турында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хәбәр иткәнчә, «Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында» 31 июль, 2020 ел, № 269-ФЗ Федераль законның 6 статьясы, «Дәүләт кадастр бәяләве турында» 3 июль, 2016 ел, № 237-ФЗ Федераль законның 11 статьясы нигезендә, министрлыкның 21.02.2022 ел, № 540-р боерыгын үтәү йөзеннән, 2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларына дәүләт кадастр бәяләве үткәреләчәк.

Дәүләт кадастр бәяләвен үткәрүгә әзерләнү эшләре 2023 елның 1 гыйнварына кадәр алып барылачак. «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ГБУ «ЦГКО»), кадастр бәясен билгеләү өчен кирәкле мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү максатыннан чыгып, дәүләт кадастр бәяләвен үткәрүгә әзерләнү этабы кысаларында, тиешле күчемсез милек объектлары хуҗаларыннан күчемсез милек объектлары характеристикалары турында декларацияләр кабул итә.

Күчемсез милек объектлары характеристикалары турында декларация формасы һәм аны карап тикшерү тәртибе «Росреестр»ның «Күчемсез милек объектлары характеристикалары турында декларацияне карап тикшерү тәртибен, шул исәптән аның формасын раслау турында» 24.05.2021 ел, № П/0216 боерыгы белән расланган.

Күчемсез милек объектларының характеристикалары турында декларацияләрне кабул итә:

ГБУ «ЦГКО». Адресы: 420021, Казан ш., Париж Коммунасы ур., 8 й.;

«Татарстан Республикасында Күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиаллары. Рәсми сайтында (https:// mfc16.tatarstsn.ru/filials-map) күрсәтелгән адреслар буенча;

электрон документ рәвешендә (көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган булырга тиеш), ГБУ «ЦГКО» электрон адресына (Gbu.Cgko@tatar.ru) юлларга мөмкин.

Бу хакта тәфсилле мәгълүматлар ГБУ «ЦГКО» сайтына (cgko.tatarstan.ru) «Услуги» бүлегенең «Декларация о характеристиках объекта недвижимости» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границ земельного участка

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом Саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06), в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:090202:563, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Матюшинское сельское поселение, д. Матюшино, объединенное некоммерческое садово-дачное товарищество «Матюшино», проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиками кадастровых работ являются Зинова Светлана Германовна, Козина Елена Германовна.

Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 22 апреля 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63 с 23.03.2022 г. по 21.04.2022 г.

Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границ земельного участка с кадастровым номером: 16:24:090201:9141, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Матюшинское сельское поселение, д. Матюшино, ул. Университетская, д. 9.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границ земельного участка

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом Саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья», уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, Мавлютова, 31А, офис 2–5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06 в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:090202:242, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Матюшинское сельское поселение, д. Матюшино, ул. Лесная, д. 1А проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Никитина Анастасия Дмитриевна.

Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 22 апреля 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2–5, тел.: 514-63-63 с 23.03.2022 г. по 21.04.2022 г.

Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границ земельного участка с кадастровым номером: 16:24:090201:239, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, д. Матюшино, ул. Лесная, 1.

Смежный земельный участок, с правообладателем которого требуется согласовать местоположение границ земельного участка с кадастровым номером: 16:24:090201:243, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Матюшинское сельское поселение, д. Матюшино, ул. Лесная, 3.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Паспорт самоходной машины ТА-311945 на погрузчик SSL-709 «TCM CORPORATION», принадлежащий ООО «Посад», в связи с утерей считать недействительным.

Кызык кеше

Сәяхәтче-табиб

Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсендә урта медицина хезмәткәре булып эшләүче, «кызыл зона»да кеше гомерләрен коткаручы Искәндәр Нурмиев турында бер язган идек инде. «ВТ» укучылары хәтерлидер: егет сәяхәт итәргә дә бик хирыс.

Яшь белгеч күптән түгел Байкал күленә барып кайтты. Аңа кадәр Эльбрус тавына менгән иде. Бергә сәяхәт итүче юлдашы да бар: үзе белән һәрвакыт үзе эшләгән хастаханәнең әләмен ала.

Бер урында тик тора һәм ялын йокы туйдырып кына уздыра торганнардан түгеллеген аңладык инде Искәндәрнең. Байкал күленә сәяхәт турында тауга менгәннән соң ук уйлана башлый. Узган елның октябрь аенда турбилет мәсьәләсен белешеп, хәл итеп куя да февральдә хыялын тормышка ашыра.

– Байкал – илебезнең иң үзенчәлекле табигый байлыгы, планетаның иң тирән күле. Сәяхәткә махсус әзерләндем дип әйтә алмыйм. Эльбрус тавына менгәндә дә шулай булды. Төркемләп, фикердәшләр белән сәяхәт итү яклы мин. Сәяхәтем 17 февральдән 24енә кадәр дәвам итте. Казаннан Мәскәүгә поезд белән, аннан Иркутск шәһәренә 6 сәгать самолетта очтык. Әле анда 5 сәгать вакыт аермасы да бар бит. Тагын бер аерма һава торышында чагылды. Без калага килеп төшкәндә 24 градус салкын иде, коры. Татарстанда бу суыкта кулга бияләй кимичә йөреп булса, биредә берничә секундка да пирчәткәсез калу мөмкин түгел. Бармаклар тиз ката. Кешеләрнең ни рәвешле кулларын өшетүләрен аңладым инде хәзер, – дип сөйләде Искәндәр.

Яшь сәяхәтченең сәфәр вакытындагы (бәлки, тормышындагы да) төп кагыйдәсе – үзеңне бернәрсәдә дә чикләмәскә. Байкалга сәяхәте, барысын да исәпкә алып, 80 мең сумга төшкән. Хис-кичерешләр, алып кайткан илһам чыганагы бу бәягә генә тора, ди ул. Үзенчәлекле ризыкларның тәмен, кояш баешының гүзәллеге әле дә тәэсирләндереп тора икән.

– Байкалда туристлар күп. Ялгышмасам, елына 2 миллионга якын кеше шушы үзенчәлекле урынны күрергә дип махсус килә. Россиядә яшәүчеләр генә түгел, хәтта Кытайдан махсус тур белән килүчеләр очрый, – дип аңлатты Искәндәр. – Бу якларда шаманлык бик көчле бит инде. Без булган утрауларның берсендә, биредә теләгән теләк 100 процент чынга ашачак, дип кызыктырдылар. Мин дә хыялларымны шунда «калдырдым».

Биредә яшәүчеләрнең тормыш-көнкүрешләре дә гаҗәпләндергән яшь егетне.

– XXI гасыр булса да, анда газ юк, утын ягып көн күрәләр. Утын кыйммәт тора. Тагын бер кызыкка тап булдым: мунча керәм дисәң, аренданың бер сәгате – 2 мең сум. Электр бәясе нык очсыз. Чагыштырып карасаң, тиеннәр чыга инде. Байкал тыюлык зонасы санала, шуңа да анда су юк, анысын шәһәрдән алып киләсе. Бер карасаң, бирегә карлы як дип күзаллап барасың. Ә асылда анда кар бик аз, юк диярлек хәтта, – дип сөйләде Искәндәр. – Байкалны нәкъ тә кышын, бозын күрәсем килгән иде. Сәяхәтемнән канәгать. Ольхон утравына үзем эшләгән 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе әләмен дә алып килдем.

Сүз уңаеннан, Искәндәр әле өйләнмәгән. Киләчәктә үзе барып күргән урыннарга кабат гаиләсе белән сәяхәт кылырга тели. Хыялындагы маршрут – Россиянең башка үзенчәлекле төбәкләре һәм Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге илләре.

– Россия мине зурлыгы һәм үзенчәлекле урыннары белән җәлеп итә. Төркия, Мисырдагы пляжда кызынып яту минем өчен түгел, – ди Искәндәр. – Әлбәттә, эчке туризм кыйммәткәрәк төшә, монысы белән бәхәсләшмим. Әмма үзебезне чикләп яшәмәсәк иде. Кемдә юк инде ул ипотека? Кемдә юк инде ул проблемалар? Гомер бер генә бирелгән, мәшәкатьләргә чумып кына яшәсәк, кызык булмас иде. Сәяхәт ул – организм өчен шәп ял, арудан котылу ысулы. Шулкадәр ерак сәфәргә чыгып, үземне нәрсәдә дә булса чикләргә җыенам икән, мин ул урынга барып та тормыйм. Күңелең ирекле булсын.

Искәндәрдән киңәшләр

- Сәяхәт иткәндә синең кызыксынуыңа туры килердәй юлдашлар булсын. Сәфәр компаниянең нинди булуына да бәйле.
- Калыплашкан фикерләрдән азат булырга кирәк. Үзең барып күрмәгән як турында начар уйлап, анда бармыйча калу – дөрес түгел.
- География белән кызыксыныгыз.
- Читкә баргач, милли кухняга игътибар итегез. Тарихи ватанында ризык тәмлерәк. Әмма теләсә кайда ашарга ярамый. Бигрәк тә ягулык салу станцияләрендә. Машиналар күпләп туктаган, гид, экскурсоводлар йөргән җирләргә барырга тырышыгыз.
- Үзегез белән кирәкле даруларны йөртегез.
- XXI гасырда яшибез. Ярдәмсез калмассыз, куркырга кирәкми.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ДҮРТ ДИПЛОМЛЫ БЕЛГЕЧ ОЛЕГ ВОЛКОВ:

«БҮРЕ КЕБЕК ҮҖӘТЛЕК ТӘ БАР»

Шөгыль

Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылында яшәүче Олег Волков, өйдә хатын-кыз кулы җитми, дип аптырап тормый. Идәнен дә юа, камыр ризыкларын да пешерә, кыяр-помидорын да тозлый. Дөньялар болай булса, ипине дә үземә салырга туры килмәгәе, ди. Оекбаш, бияләй дә бәйли. Эшне талымлап тора торганнардан түгел.

Питрәч

Волковлар нәселенең кушаматы – Бүре. Тырышлык, үҗәтлек Олегның холкында да чагыла. Шул ук вакытта йомшаклык та хас, кешегә бер дә «юк» дип әйтә белми. Әмма теләгенә ирешмичә, ярты юлда туктап калырга яратмый. Авылда кемнең дүрт югары дипломы бар әле?! Агроном, биология укытучысы, психолог, музей белгече. 45 яшьлек Олег менә шуның кадәр һөнәргә ия. Баштарак мәктәптә биология дәресләрен укытса, хәзер авылның туган якны өйрәнү музеен җитәкли. Керәшеннәрнең мәдәниятен, көнкүрешен яктырту буенча эш алып бара.

Керәшен Сәрдәсендә яшәү урыны буенча 300ләп кеше теркәлгән, әмма шуның яртысы гына авылда яши. Укыганым әрәмгә китә дип, авылдан китү ягын карамаган Олег. Җирне ярату хисе шәһәргә тартылудан көчлерәк булып чыккан. Яшелчәчелек белән шөгыльләнү бабасыннан күчкән. Бакчада казыну аның бар мәшәкатен оныттыра. Ике теплицада яшелчә үстерә.

Тәрәзә төбе үсентеләр белән тулган. Борыч, кәбестә чәчкән. Помидор утыртырга март ахыры – апрель башын көтә. Аны өйдә ике айдан артык үстерергә киңәш итми. Үсентеләрен ел саен ала торган клиентлары бар икән. Лалә, гладиолус суганчаларын да сата.

– Бездә һәр гаилә яшелчә, җиләк-җимешне үзенә кирәгенчә генә үстерә. Әгәр уңышны авылга килеп җыючылар булса, сату өчен үстерүчеләр дә табылыр иде, – ди бакчачы. – 2019 елны бәрәңге уңышы күп булды, аны кая куярга белмәдек. Килосын 5 сумга саттык. Авылдашларның күбесе ашалмаган бәрәңгесен яз көне чыгарып ташлады. Узган ел уңыш белән мактана алмадык. Быел бәрәңге мәйданын арттыручылар күбрәк булыр дип уйлыйм. Ник дигәндә, 90 нчы еллардагы кебек, шәһәрдән кайтып, авылда бәрәңге утыртырга теләүчеләр бар.

Олег Волков помидорның «Москвич», «Сибирская малютка», «Джина» кебек иртә өлгерә торган сортларын утырта. Соңгы вакытта «Хөрмә», «Снегирь», «Подснежник» дигәнен үстерә башлаган. Кыярларның «Кураж», «Клавдия», «Верные друзья» кебек сортларын тәкъдим итә. Бакчачы әйтүенчә, ике-өч сортны бер түтәлгә чәчәргә кирәкми, бу дүртенче яңа сорт барлыкка китерәчәк. Бер теплицада баллы белән әче борычны да утырту файдага түгел, баллысы әчегә әйләнәчәк. Ак белән кызыл чөгендерне дә аерым чәчәргә кирәк, бергә кушылганда, төсләре буталачак. Виктория уңышы яхшы булсын өчен, кишәрлекне ел саен бер түтәлгә арттырып, берничә елдан беренче утыртканын бетерергә кирәк. Кыяр әче булмасын дисәң, орлыгын сирәк чәч, суны кызганма.

Олег Волков яшелчәне үстереп кенә калмый, көзге уңыштан кышка җитәрлек запас та әзерли. Елга ким дигәндә өчәр литрлы 50–60 банка чия, карлыган компотлары яба. Ясаган салатларының саны гына 100 банкадан артып китә. Кыяр, помидор да тозлый. Үзенә ашарга да, туганнарына күчтәнәчкә бирергә дә җитә.

– Күбрәк кәбестә, борщлар ябам. Шулпаны пешергәч, тиз генә салырга җайлы. Кишерен, суганын, кәбестәсен турап торасы юк. Сезон вакытында көнгә 4–5 сәгать плитә янында кайнашам. Мине бер генә төрле эш туйдыра. Шуңа күрә берьюлы берничәне башкарам, – ди Олег.

Олег – гаиләдә иң төпчеге. Әнисе аны 36 яшендә тапкан. Апасы шәһәргә киткәч, бар эш тә энекәшенә калган. Әнигә ярдәм итәм дип, йон эрләргә дә, оекбаш, бияләй бәйләргә дә өйрәнгән. Тулай торакта яшәүче апасына кунакка баргач, кухняда хуҗабикәләрнең кыяр-помидор тозлаганын күзәткән. Шуннан үзе дә тозлау эше белән кызыксына башлаган. «1993–1994 елларда кибеттә сатып алырга әйбер булмады бит. Бәрәңге белән кышка дип ясалган салат ашап, кытлыкны җиңдек», – ди Олег.

Аш-су рецептларын китаптан да карап өйрәнгән, кунакка баргач, тәмлеләренең ничек әзерләнүен сорашкан. Хәзер, киресенчә, авылдашлары, танышлары аның үзеннән сорый. Шулай итеп, рецептлары кулдан-кулга йөри.

– Тәме түгел, күбрәк сакланышы өчен борчыласың. Хәзер компотны җимешләрен дә кайнатып әзерлим. Рецептта уксус күп тоелса, киметеп салам. Гомумән, тоз, шикәр комын йә киметеп, йә арттырып тәмне көйләргә тырышам. Берничә банкага дигән тозлыкны зур кәстрүлгә салып кайнатам. Бу вакытта тәме бертөрле була, – ди.

Моңа кадәр берәүнең дә Олегка, нигә хатын-кыз эше эшлисең, дип әйткәне булмаган. Әйтсә дә, үпкәләмәячәк, әллә ни исе китмәячәк. Киресенчә, аның белән горурланучылар күбрәк икән. Икенче тапкыр өйләнергә дә исәбе юк кебек. Аның шәһәргә китәсе, ә кызларның авылга кайтасы килми. Шуңа күрә әлегә Олегка пешерергә дә, юарга да туры киләчәк. Ау, кызлар сез кайда?

Сәрия МИФТАХОВА

«ЗӨЛФИЯ» САЛАТЫ

Кирәкле әйберләр: *помидор – 3 кг, баллы борыч –1 кг, башлы суган – 250 г, кишер – 0,5 кг, петрушка, укроп – 100 г, сарымсак – 30 г, лавр яфрагы – 5 данә, борчаклы борыч, канәфер – 12шәр, сыек май – 100 мл, шикәр комы – 100 г, аш серкәсе – 50 мл, дарчин – ярты чәй калагы (сылама).*

Яшелчәләрне турап, кишерне исә угычтан уып, барлык кирәкле әйберләрне кушып, тәменчә тоз (3 аш кашыгыннан артык түгел), төелгән борыч салып утка куябыз. Кайнап чыккач, 40 минут кайнатабыз, бераз болгаткалап алабыз. Кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга ябабыз.

БӘХЕТСЕЗ ТҮГЕЛ УЛ!

Язмышлар ярында

Бу гаиләдә беркем дә зарлануны белми. Ике авыру бала үстергән әни кеше дә, тормыш авырлыкларына бирешмичә, үзләренең сәләт-уңышлары белән сокландыручы Фәнис һәм Эльвина да.

Балтач

Моннан унҗиде ел элек мин бу гаиләдә булып, «Дүрт стена эчендә... бай дөнья» дип, ул чакта мәктәп укучысы булган Фәниснең күңел байлыгына сокланып язган идем. «Аның дөньясы дүрт стена белән чикләнә. Якыннары, вакыт табып, ишегалдына алып чыгуны исәпкә алмаганда. Егетнең фикерләве, тормышка карашы да әнә шуңа тәңгәл булырга тиеш иде кебек. Әмма...» – дигәнмен дә ул язмамда Фәниснең дөнья хәлләре, шигърият, музыка дөньясы белән танышып баруына, бигрәк тә рус әдәбиятына баш-аягы белән гашыйк булуына сокланып язганмын. Тумыштан церебраль паралич дигән чир аякларына уралган малай ике яшьтән ундүрт яшькәчә гел тернәкләндерү үзәкләрендә дәвалана. Бер барудан дүртәр ай кайтмаган малай русчаны су урынына эчә, шунлыктан өйдә рус мәктәпләре программасы буенча белем ала. Рус әдәбиятына мәхәббәте дә шуңа бәйле була.

«Мин үземне бәхетсез дип әйтә алмыйм, – дип тә сокландырган иде Фәнис ул чакта. – Мине яратучы әнием, туганнарым бар. Тормышта бер нәрсә дә безнең кодрәттән генә тормый. Бу ник болай булган, ник тегеләй, дияргә кирәкми. Без, кешеләр, гөнаһ кылганга, җиргә сөрелгәнбез бит. Үзебезгә бирелгән язмышны зарланмыйча үтәргә генә кирәк».

Аның ул чакта бар курыкканы... мәктәп тәмамлагач, «олы дөнья» белән бәйләнеше өзелү иде. Төгәлрәге, үзен бәяли, аңлый белгән кешеләр белән элемтә югалудан курка иде. Чөнки өйләренә килгән укытучылары аңа үзләренә тиешле сәгатьтә дәрес биреп кенә кайтып китмәгән, тыңлаганнар да, төрле темага Фәнис белән иркенләп сөйләшкәннәр дә. Ул чакта бит әле мөмкинлекләре чикле кешеләр күбрәк үз эчләренә бикләнгән, алар турында язмыйлар да, искә дә алмыйлар иде...

Аннан соң үткән унҗиде ел эчендә җәмгыятебездә күп үзгәрешләр булды. Инде мөмкинлекләре чикле кешеләр дә үзләренең гаҗәеп адымнарга сәләтле булуларын расладылар. Аларның күбесе актив тормыш алып бара. Язмам герое Фәнис тә – районда, республика, ил күләмендәге күп төрле ярышларда җиңү яулаган спортчы.

– Моннан берничә ел элек безгә районыбыздагы минем кебек күп егет-кызларга ярдәм кулы сузган Фагыйль абый Гайнетдинов килде, – дип сөйли Фәнис. – Боччо дигән спорт уены бар, шөгыльләнеп карамыйсыңмы, диде. Боччо турында ишеткәнем булмаса да, теләр-теләмәс кенә «ярар» дидем. Ул мине Яшел Үзән шәһәреннән килгән тренер Ираида Николаевна белән таныштырды. Бераз шөгыльләнүгә, Түбән Камага Татарстан беренчелегенә бардык. Һәм мин анда өченче урын алдым. Шуннан китте инде. Саратов, Новосибирск, Севастополь... – бик күп шәһәрләрдә булдым.

Барган бер генә ярыштан да медальсез кайтмый Фәнис. Фатирларында стенага эленгән ул медальләр – әнисе Нина-Наиләнең иң зур горурлыгы. Бөтен ярышларга да улын үзе йөртә әни кеше. «Ярышларга йөрү бик чыгымлы. Ярый әле, Татарстан командасы составында булгач, алдагы елларда республикадан ярдәм иттеләр. Хәзер тәртибе ничек икәнен белмибез, пандемия башланганнан бирле ярышларга йөрмибез, чөнки Фәниснең бер генә прививкасы да юк», – ди ул.

Наилә апа – Зәй районының Сәвәләй авылы кызы. Булачак тормыш иптәше Балтач районының Кариле авылы егете Рәфкать Сөләйманов белән Әлмәттә төзелеш техникумында укыганда танышалар. Бик яшьли өйләнешәләр. Ире бакыйлыкка китеп барганда нибары 28 яшь була аңа, берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән тол кала. Аны туганнары гына Нина дип белә, балтачлылар өчен күптән Наилә инде ул...

Язмыш диген, икенче ире дә яшьли вафат була Наилә апаның. Алты баласын берьялгызы аякка бастыра ул. Зарланмый, сыкранмый. Әле бит Эльвинасы да арка мие бүсере белән туа, берничә операцияләр ясатсалар да, авыруны тәмам җиңә алмыйлар. Ярый әле урында калмады, буй үсеше тоткарланса да, бик зиһенле, бер таякта йөгереп йөри, дип сөенәләр. Алай гына да түгел, Эльвина – өйдәге бар эшләрдә әнисенең уң кулы. Пешерә, җыештыра, тәртипле. Күптөрле кул эшләре белән дә мавыга. Бисердан чәчәкләр, сувенирлар да эшләгән, соңгы вакытта номерлар буенча картиналар буяу белән дә, фотога төшерү, мозаика буенча бисердан катиналар ясау белән дә шөгыльләнә. Өстәвенә искиткеч ачык, шат күңелле, эчкерсез әңгәмәдәш.

Хәер, Фәнис тә, Наилә апа үзе дә шундый. Бөтенесен шундый җиңел итеп, көлеп сөйлиләр – әйтерсең, бер авырлык күрмәгәннәр! Гомере буе төзелештә эшләгән Нина-Наилә апа, инде лаеклы ялда булса да, әле дә эшсез тормый. Кулы алтын кешегә эш бетми, штукатурчы-малярларны чакырып кына торалар. Гаиләсен муллыкта, бөтенлектә яшәтү өчен тырышкан көне. Дөрес, гаилә корган балалары, оныклары да бу фатирга эзне суытмый. Бергә булганда бөтен авырлыкны да җиңеп буласына ышанган инде алар.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 240

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+